Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Якушкино авылы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАРЫ

«13» ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге Якушкино авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Якушкино авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2021 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Якушкино авылында су белән тәэмин итү объектларын норматив хәлгә китерү;

Якушкино авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту.

Халык җыенында рәислек итүче: Х.Х.Хәмидуллин

Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Хәмидуллин